ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Колхозная, дом 1,
село Шланга, 422474
ИНН 1617003275

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Колхоз урамы, 1нче йорт,
Шланга авылы, 422474

Тел.: (84375) 3-91-36, 8(9377754063), факс: (84375) 3-91-36, e-mail: Shlang.Drz@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 11 августы №10

Шланга авыл җирлегенең сайлау участогы территориясендә агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә карар бирәм:

1. 1359 нчы сайлау участогы территориясендә агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга:

Шланга авыл җирлегенең административ бинасында (адресы: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Шланга авылы, Ленин урамы., 32 йорт);

ТР, Чүпрәле районы, Шланга авылы, Мәктәп урамы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан «Голия» кибете бинасында;

ТР, Чүпрәле районы, Шланга авылы, Партизан урамында көндәлек куллану кибете бинасында;

ТР, Чүпрәле районы, Шланга авылы, Ленин урамы, 21 йорт адресы буенча урнашкан ОПС бинасында;

Шланга урта мәктәбе бинасында (адресы: ТР, Чүпрәле районы, Шланга авылы, Ленин урамы, 26 йорт).

2. Шланга авыл җирлеге башлыгының 2019 елның 1 августындагы 15 номерлы « Шланга авыл җирлегенең сайлау участогы территориясендә агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге башлыгы: А. А. Мөхәррәмов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНН 1617003275